РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.12.2021 с. Куралово 36

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрен әзерләү һәм уздыру чорында социаль әһәмиятле объектларның, кешеләр күпләп була торган урыннарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм гражданнарның иҗтимагый иминлеген тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге Уставы нигезендә, гражданнарның һәм юридик затларның тормышын, сәламәтлеген, мөлкәтен, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне 2021-2022 еллардагы Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрен бәйрәм итү чорында янгыннардан саклау максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге халкы тарафыннан пиротехника әйберләрен куллануның махсус урыннарын билгеләргә:
Куралово авылы (Сулица тугае, үзәк юлдан - уңнан һәм сулдан)
Рус Борнашы авылы - (Олы урамдагы Сулица елгасы тугае)
2. Раштуа бәйрәмнәрен уздырганда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, социаль әһәмияткә ия объектларны саклауны көчәйтү буенча җаваплы зат итеп Куралово авыл җирлеге башлыгы К.Г.Квашневны билгеләргә.

3. Әлеге карарны Куралово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Куралово авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе: Т.Ю.Тимиряева